# Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай

(1886-1913)

Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
Зеленая Роща төп белем бирү мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Фәтхуллина Рәйсә Габделсамат кызы

**Габдулла Тукай 1886 нчы елның 26 нчы апрелендә Казан өязе Мәңгәр волосте Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә туа.**



# Г.Тукайның әти-әнисе



**Мөхәммәтгариф**



**Мәмдүдә**

Азмы какканны вә сукканны
күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик
маңгаемнан милләтем...

**Габдуллага 4 ай ярым булганда, аның әтисе вафат була. Әнисе, әле ире үлгәч тә, бер елга якын Кушлавыч авылында яши. Аннары ул улы белән әтисе йортына – Өчилегә кайта. 1889 нчы елның 3 нче гыйнварында Сасна Пүчинкәсе авылы мулласына кияүгә чыгарга мәҗбүр була. Ул ике яшьлек баласын вакытлыча Кушлавычтагы Шәрифә исемле күрше карчыкка калдыра, ә бераздан улын үзе янына алдыра. Әмма бу бәхетле тормыш озак бармый, әнисе үлеп китә. 4 яшендә Габдулла бөтенләй ятим кала.**



**Кечкенә Тукай.**
**Рәссам Х.Казаков.1958.**

# Кушлавыч –Өчиле - Сасна - Өчиле

* **1890 нчы елда Габдулланы үги әтисе Өчилегә бабасы Зиннәтуллага кайтарып куя.**




# Казан- Өчиле

* **күп балалы Зиннәтулла бабай Габдулланы Казанга җибәрә.**
* **1890-1892 нче елларда ул һөнәрче Мөхәммәтвәли абзый белән Газизә апа гаиләсендә яши. Аның яңа әти-әнисе кинәт кенә авырып китәләр, шуңа күрә кечкенә Габдулланы яңадан Өчилегә кайтаралар.**



# Кырлай

* **1892-1895 нче елларда Габдулла Кырлайда игенче Сәгъди абзый һәм Зөһрә апа гаиләсендә яши.**



**Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл -**
**Кырлай диләр;**
**Җырлаганда көй өчен “тавыклары**
**җырлай” диләр.**
**Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз**
**торган идем,**
**Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем,**
**урган идем...**